ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «___» декабреннән № ____

2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк өзеклекләр белән гомуми мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына торак урыннарны карап тоткан өчен хезмәтләр төрләре буенча түләү күләмен кушымта нигезендә билгеләргә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына күпфатирлы йортта гомуми милектән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган, торак урынны карап тоткан өчен түләү

күләменә кирә торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан билгеләнә дип билгеләргә.

3. Күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләрнең составына, күпфатирлы йортның конструктив һәм техник үзенчәлекләренә карап исәпләнә һәм үзгәрә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының торак фондында  торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында» 2024 елның 17 декабрендәге 311 номерлы карары 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көчләрен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «___» декабрендәге
____ номерлы карарына
кушымта

2026 елга социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләренә торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләме

| № п/п | Түләүнең исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (1 сум). | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2026 30.06.2026 | 01.07.2026 31.12.2026 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 4,42 | 5,52 |
| 2 | Күпфатирлы йортның гомуми мөлкәте составына керә торган гомуми файдаланудагы урыннарны карап тоту, шул исәптән: | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | | |
| 2.1 | - йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру; | | 9,29 | 11,22 |
| 2.2 | - йорт яны территориясен җыештыру; | | 3,99 | 4,81 |
| 2.3 | - дератизация (дезинсекция); | | 0,17 | 0,17 |
| 3 | Бинаның төзелеш корылмаларына, инженерлык системаларына һәм башка гомумйорт милкенә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | | |
| 3.1 | - торак бинаны; | | 11,36 | 13,72 |
| 3.2 | - йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын; | | 4,47 | 5,4 |
| 3.3 | -йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләре һәм электр җиһазлары; | | 0,54 | 0,66 |
| 3.4 | - күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын; | | 0,35 | 0,37 |
| 3.5 | - күпфатирлы йортларның вентиляция һәм төтен каналларын | | 0,79 | 0,79 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тикшерү (карау) һәм чистарту: | | | |
| 3.6 | - күпфатирлы йортларда мичләрне, каминнарны һәм учакларны (төтен юлларын) тиешле тәртиптә тоту максатларында башкарыла торган эшләр | | 1,25 | 1,32 |
| 4 | Эчтәге газ җиһазларын техник диагностикалау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү вакыты башланганчы 12 ай эчендә башкарыла) | кв. м. аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 | 1,00 |